| Республика Татарстан<br>Совет Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Югары Чыршылы<br>авыл җирлеге Советы |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2024 №2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында «Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктына, Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставына нигезләнеп, Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 5.5 пунктны 13 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Н.Камалетдинов